***Гомәров И.Г.***

# Яков Емельянов шигъриятен өйрәнү юлында

***(Фәнни язмалар. - Казан: Ихлас, 2010. - Б. 56-59.)***

XIX гасыр шагыйре Яков Емельянов иҗаты татар әдәбиятының үзенчәлекле һәм кабатланмас сәхифәсен тәшкил итә. Бу үзенчәлек аның керәшеннәр арасыннан чыккан беренче шагыйрь булуы белән генә түгел, ә XIX йөз татар иҗтимагый-мәдәни тормышының мөһим мәсьәләләрен христиан дине вәкиле, тагын да төгәлрәк әйткәндә, дини дәрәҗәләргә ирешкән христиан руханые күзлегеннән бәяләве белән билгеләнә. Бу хезмәтебездә без әлеге үзенчәлекне Яков Емельянов иҗатының жанр һәм стиль сыйфатларын билгеләү аша ачуны максат иттек. Стиль төшенчәсе әдипнең кабатланмас язу манерасы рәвешендә генә алынмыйча, киңрәк планда, “сәнгать әсәренә хисси тәэсир һәм эмоциональ, эстетик рәвеш бирүче, аның экспрессив-бәяләүче мәгънәсен ачыклый торган әдәби форма элементлары” бердәмлеге буларак алынды.

Яков Емельянов хакында тәүге мәгълүматлар 1896 елда “Православный собеседник” журналында остазы миссионер Николай Ильминскийның керәшен татарларына юлланган хатларында китерелә. Шушы елдан алып бүгенгәчә аның иҗаты Г.Толымбай, А.Григорьев, Х.Госман, М.Гайнуллин, М.Глухов, Р.Әхмәт, Х.Миңнегулов, Р.Фәйзуллин, И.Халиков һ.б. әдип-галимнәр хезмәтләренең тәфсилле тикшерү объекты булды. Әмма шул ук вакытта бу шагыйрь иҗатында ак таплар, нәмәгълүм фактлар бүген дә кала килә. Әйтик, китапларының басылу тарихы, язган әсәрләренең саны турында төрле хезмәтләрдә төрле фикерләр китерелә. Аларда ук күрсәтелгәнчә, Яков Емельяновның 1874 елда Казандагы Духовная академиягә укырга керү факты да тагын бер кат өйрәнүне һәм раслауны сорый (чөнки Духовная академиягә укырга керү хокукы дини семинария тәмамлаучыларга гына бирелгән). Шигырьләренең гомуми саны буенча да шундый ук хәл. Мәгълүм булганча, Яков Емельяновның әсәрләре ике китап рәвешендә, беренчесе 1879 елда

“Стихи на крещено-татарском языке. Дьякон Я.Е.Емельянов стихлары” исеме белән “Изге Гурий бердәмлеге” ярдәме, икенчесе 1888 елның 17 мартында “Православия миссионерлар җәмгыяте”нең матди ярдәме белән “Стихи на крещено-татарском языке” исеме астында, авторы күрсәтелмичә дөнья күрә. Әдәбият галиме Гомәр Толымбай беренче җыентыкта ун шигырь – “Санлау”, “Кайгы”, “Ярлы тормыш”, “Чәй”, “Нардуган”, “Саташканны уяту”, “Олысыманлык”, “Әләк”, “Көн дә ызгыш”, “Күремчене хөрмәтләү” әсәрләре барлыгын искәртә. Галим Рәфис Әхмәтов алда саналган әсәрләргә “Кайгылы чакта көенмә”, “Ходай сине илдән алган” исемле ядкярләрне дә өстәп беренче җыентыкта басылган шигырьләрнең санын уникегә җиткерә. Хаклы рәвештә сорау туа: ни өчен соң төрле галимнәр Яков Емельянов шигырьләренең санын төрлечә күрсәтә? Хикмәт аларның җыентыкта бер-бер артлы килгән һәм бер үк темага – им-том, күрәзәчелек белән шөгыльләнүчеләрнең ялганнарын фаш итеп язган өч аерым шигырьне бер әсәр – “Күремчене хөрмәтләү” шигыре итеп карауларында. Дөрес, “Ялкау мескен, зур ялганчы...”, “Бүген күргән төшемне...” дип башланып киткән шигырьләр тематик һәм уздырылган фикернең логик эзлеклелеге ягыннан “Күремчене хөрмәтләү” әсәренең дәвамы булырга хаклы. Шуңадыр күрәсең, әдәбият галиме Мөхәммәт ага Гайнуллин да “Татар әдәбияты. XIX йөз” хезмәтендә аларны укучыга бер шигырь итеп тәкъдим иткән. Әмма, безнең уебызча, алар һәрберсе аерым әсәр буларак өйрәнелә, ә бергәлектә шигъри цикл итеп карала ала, чөнки игътибар белән караганда алардагы стиль төрлелеген күрми үтү мөмкин түгел. Әйтик, “Күремчене хөрмәтләү” тулысы белән Ана, бала һәм күрәзәче Дарҗа әбинең үзара сөйләшеннән, ягъни диалоглардан гыйбарәт, ә “Бүген күргән төшемне...”, “Ялкау мескен, зур ялганчы...” дип башланучы шигырьләр диалог формасына корылмаган, ягъни бу стиль аларда сакланмаган. Шул ук вакытта бу ике әсәр үзара да бер-берсеннән аерылып тора. Бу аерымлык шигырьләрнең адресатына игътибар иткәндә ачык сизелә. “Бүген күргән төшемне...”, шигыре “Синең өеңә күремче керсә, / Саклаучы фәрештәң көенер, / Күремче дусы, зәһәр шәйтан, /

Шул чагында сөенер!” дип авторның турыдан-туры укучыга мөрәҗәгате белән бетсә, “Ялкау мескен, зур ялганчы...” ядкяре күрәзәчелек белән шөгыльләнүченең ахирәттәге газапларын тасвирлаганнан соң, аларга ук эндәшкән “Күргән төшнең куркынычын / Барыгыз да сизегез, / Яман эштән, ялганнардан / Сез, күрәзәләр, бизегез” дигән юллар белән тәмамлана. Димәк, шигырь адресатларының төрлелеге аларны мөстәкыйль әсәрләр буларак өйрәнү мөмкинлеген тагын бер кат раслый.

Димәк, Яков Емельяновның беренче китапта ундүрт, икенче җыентыкта яңа 5 шигыре (“Кояш”, “Балам”, “Улым”, “Әби үгете”, “Кенәгәсен кулына тотып...” әсәрләре) нәшер ителгән дип әйтә алабыз. Шуларга цензура аша үтмәгән, Н.Ильминскийга юлланган хатында кулъязма хәлендә сакланып, безнең көннәргә килеп җиткән “Саран бай” әсәрен дә кушсак, аларның саны егермегә җитә. Димәк, Яков Емельяновның әдәби мирасы үз эченә егерме шигырьне берләштерә икән. Дөрес, алга таба бу санның үзгәрү ихтималы да юк түгел. Аерым бер әсәрләре кулъязмаларда, остазлары миссионерлар Н.Ильминский, В.Тимофеев һәм башкаларга атап язылган хатларында сакланып калырга мөмкин. Бу юнәлештә әле шактый эш башкарырга кирәклеге көн кебек ачык.

Әдәбият галиме Хатыйп Госман үзенең мәгълүм бер хезмәтендә хаклы рәвештә “Чиркәү Я.Емельяновны электән килә торган татар язма поэзиясе традицияләреннән аерып куйды. Аның каравы, Емельянов татар халкының борынгыдан килә торган авыз иҗатыннан, телдән әйтелә торган поэзиясеннән, тирәнрәк чумып, бай традиция алды, бу поэзиядә башка шагыйрьләр күрә белмәгән яңа мөмкинлекләрне ачты, ачыграк әйткәндә, татар иркле шигыренең орлыгын табып чыгарды һәм үстерә башлады”, - дип билгеләп үткән иде.[1] Чыннан да, бу шагыйрь үз иҗаты белән XIX гасырның шәркый стиль өстенлек иткән традицион шигърият кысаларына гына сыешмыйча, һәм идея-тематик һәм поэтик яссылыкта яңа үрләр яулады, татар сүз сәнгатенең яңа иҗади мөмкинлекләре барлыгын раслады. Яков

[1] Госман Х. Егерменче елларда татар поэзиясе. Казан, КДУ. - 1964. - 15 бит

Емельяновның шигъри дөньясы турында сөйләгәндә, иң беренче чиратта, аның шушы чор татар мохитының актуаль мәсьәләләренә православие юнәлеше руханые буларак бәя бирүен, тормыш-яшәешне христиан дине әхлакый кыйммәтләре аша кабул итүен искәртү урынлы булыр. Ә бу исә безнең сүз сәнгатебездә моңа кадәр күрелмәгән яңа күренеш, яңа бер сәхифә иде. Без никадәр генә "Кайгылы чакта көенмә", "Ходай сине илдән алган", "Саташканны уяту" "шигырьләреннән тыш аның иҗатында миссионерлык рухы белән сугарылган башка әсәрләр очрамый"[2], "иҗатында ислам динен тәнкыйтьләү, христиан динен мактау азчылык урынны алып тора" дип расларга тырышсак та алда искәртелгән үзенчәлекләрне күз уңында тотмаганда бу шагыйрь иҗатын бөтен тулылыгы һәм тирәнлеге белән аңлый, аңлата алмыйбыз. Әмма шул ук вакытта икенче бер мөһим моментны – Яков Емельяновның татар милләтенең улы, актив бер шәхесе, шагыйре икәнлеген онытырга да һич хакыбыз юк.

Жанрлар турында сөйләгәндә дә, язучының иҗатында газәл, касыйдә, мәдхия-мәрсия, робагый кебек традицион жанрларның бөтенләй кулланылмавы күзгә ташлана. Хәер, аларның булмавы ниндидер гайре табигый хәл түгел, киресенчә закончалыклы күренеш. Христиан дине вәкиле буларак, Яков Емельянов шәркый поэтик традиция кысаларыннан читтә. Бу иң әүвәл, шагыйрьнең силлабик шигырь төзелешендә иҗат итү нәтиҗәсе күрәсең. Бу урында мөһим саналган тагын бер мәсьәләгә игътибар итми мөмкин түгел. Диакон Дмитрий Сизовның интернет челтәренә куелган "О. Иаков Емельянов, кряшенский священник и поэт" хезмәтендә[3] шагыйрьнең силлабик шигырь төзелешен куллануы рус китап поэзиясе, чиркәү шигърияте традицияләренең тәэсире дип күрсәтелә. Безнең уебызча, бу – мәсьәләгә бер яклы гына бәя бирү. Шагыйрьнең силлабикада язуы иң әүвәл, аның халык авыз иҗаты, татар халкының җыр традицияләрен дәвам итүе белән бәйле.

[2] Әхмәтов Р. Яков Емельянов / Р.Әхмәтов. Татар әдәбияты тарихы. Икенче том. – Казан: Татар. кит. нәшр., - 465 б.
[3] http://kds.eparhia.ru/bibliot/dipl/sizov/

Шигырьләренең 6-6, 8-8, 8-7, 9-8 һ.б. иҗек үлчәмнәрендә язылуын да исәпкә алсак, бу фикернең бәхәссезлеге тагын бер кат раслана.

Әдәби әсәрләрдә стильнең бөтенлеге стиль доминанталары системасында ачык күренә. Шундыйларның берсе – автор сөйләменең аһаңен, яңгырашын, тизлеген белдерүче интонация. Яков Емельянов шигырьләре арасында күтәренке, оптимистик (“Кояш”, “Кайгы”) интонациягә корылганнары белән бергә сагышлы, экзистенциаль яңгырашка (“Әләк”, “Ярлы тормыш”) нигезләнгәннәре дә бар.

Сөйләм стиле ягыннан караганда аның шигырьләрендә риторик сөйләм төре өстенлек алган. Бу авторның үз шигырьләрендә нәсыйхәтче ролен башкаруы белән дә билгеләнә дип уйларга нигез бар.

**Әдәбият:**


1. Әхмәтов Р. Яков Емельянов / Р.Әхмәтов. Татар әдәбияты тарихы. Икенче том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. - Б.462-473.
2. Госман Х. Егерменче елларда татар поэзиясе. Казан, КДУ. - 1964. - 287 б.
3. http://kds.eparhia.ru/bibliot/dipl/sizov/